**УКАЗ**
РАИСА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
РӘИСЕ
**УКАЗЫ**

**Татарстан Республикасында 2025 елны Ватанны саклаучылар елы дип игълан итү турында**

1941–1945 еллар Бөек Ватан сугышында совет халкы яулаган җиңүнең тарихи әһәмиятен исәпкә алып, Бөек Ватан сугышы ветераннарына һәм тыл хезмәтчәннәренә, сугыш хәрәкәтләре ветераннарына, махсус хәрби операциядә катнашучыларга һәм аларның гаиләләренә төрле яклап ярдәм күрсәтү максатында **карар бирәм:**

1. Татарстан Республикасында 2025 елны Ватанны саклаучылар елы дип игълан итәргә.

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына:

бер ай вакыт эчендә Татарстан Республикасында Ватанны саклаучылар елын уздыру буенча оештыру комитеты төзергә һәм аның составын расларга;

өч ай вакыт эчендә Татарстан Республикасында Ватанны саклаучылар елын уздыруның төп чаралар планын эшләргә һәм расларга.

3. Татарстан Республикасы муниципаль районнары һәм шәһәр округлары башлыкларына муниципаль берәмлекләр территорияләрендә Ватанны саклаучылар елы кысаларында чаралар уздыру эшен оештырырга.

4. Федераль башкарма хакимият органнарының Татарстан Республикасы буенча территориаль органнарына, җәмәгать берләшмәләренә һәм оешмаларга Татарстан Республикасында Ватанны саклаучылар елын әзерләүдә һәм уздыруда актив катнашырга тәкъдим итәргә.

5. Республика «Татмедиа» матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгына, республика һәм җирле массакүләм мәгълүмат чараларына Татарстан Республикасында Ватанны саклаучылар елын уздыруны киң яктыртуны тәэмин итәргә.

6. Әлеге Указ аңа кул куелган көннән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы Рәисе** **Р.Н. Миңнеханов**

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ РӘИСЕ АДМИНИСТРАЦИЯСЕ ГОМУМИ БҮЛЕК ОБЩИЙ ОТДЕЛ АДМИНИСТРАЦИЯ РАИСА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

Казан, Кремль
2024 ел, 27 сентябрь
№ 748